**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Об индексации денежного вознаграждения лиц, замещающих государственные должности Республики Татарстан**

В соответствии с частью 3 статьи 14 Закона Республики Татарстан от 4 марта 2006 года № 16-ЗРТ «О государственных должностях Республики Татарстан» **постановляю:**

1. Повысить (индексировать) с 1 октября 2017 года в 1,049 раза денежное вознаграждение лиц, замещающих государственные должности Республики Татарстан, установленное в соответствии с Законом Республики Татарстан от 4 марта 2006 года № 16-ЗРТ «О государственных должностях Республики Татарстан» и Указом Президента Республики Татарстан от 27 марта 2006 года № УП-122 «О денежном вознаграждении лиц, замещающих государственные должности Республики Татарстан» (с изменениями, внесенными указами Президента Республики Татарстан от 29 декабря 2006 года № УП-597, от 12 октября 2007 года № УП-538, от 28 апреля 2008 года № УП-168, от 6 мая 2010 года № УП-295, от 15 июля 2010 года № УП-461, от 2 сентября 2010 года № УП-585, от 21 апреля 2011 года № УП-230, от 6 августа 2011 года № УП-480, от 2 августа 2013 года № УП-705, от 22 октября 2013 года № УП-1031, от 10 апреля 2014 года № УП-348 и от 8 июня 2017 года № УП-480) и увеличенное (индексированное) в соответствии с указами Президента Республики Татарстан от 4 сентября 2008 года № УП-442 «Об индексации денежного вознаграждения лиц, замещающих государственные должности Республики Татарстан», от 29 октября 2008 года № УП-544 «Об индексации денежного вознаграждения лиц, замещающих государственные должности Республики Татарстан», от 13 августа 2012 года № УП-645 «Об индексации денежного вознаграждения лиц, замещающих государственные должности Республики Татарстан» и от 26 сентября 2013 года № УП-940 «Об индексации денежного вознаграждения лиц, замещающих государственные должности Республики Татарстан».

2. Установить, что при повышении (индексации) денежного вознаграждения лиц, замещающих государственные должности Республики Татарстан, его размеры, а также размер ежемесячного денежного поощрения подлежат округлению до целого рубля в сторону увеличения.

3. Кабинету Министров Республики Татарстан осуществлять финансовое обеспечение расходов, связанных с реализацией настоящего Указа, в пределах бюджетных ассигнований, предусмотренных в бюджете Республики Татарстан на соответствующий финансовый год.

4. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань,Кремль
11 августа 2017 года
№ УП-667

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларны акчалата бүләкләүне индексацияләү турында**

«Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» 2006 елның 4 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 14 статьясы 3 кисәге нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларны «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» 2006 елның 4 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларны акчалата бүләкләү турында» 2006 елның 27 мартындагы ПУ-122 номерлы Указы (Татарстан Республикасы Президентының 2006 елның 29 декабрендәге ПУ-597 номерлы, 2007 елның 12 октябрендәге ПУ-538 номерлы, 2008 елның 28 апрелендәге ПУ-168 номерлы, 2010 елның 6 маендагы ПУ-295 номерлы, 2010 елның 15 июлендәге ПУ-461 номерлы, 2010 елның 2 сентябрендәге ПУ-585 номерлы, 2011 елның 21 апрелендәге ПУ-230 номерлы, 2011 елның 6 августындагы ПУ-480 номерлы, 2013 елның 2 августындагы ПУ-705 номерлы, 2013 елның 22 октябрендәге ПУ-1031 номерлы, 2014 елның 10 апрелендәге ПУ-348 номерлы һәм 2017 елның 8 июнендәге ПУ-480 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) нигезендә билгеләнгән һәм Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларны акчалата бүләкләүне индексацияләү турында» 2008 елның 4 сентябрендәге ПУ-442 номерлы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларны акчалата бүләкләүне индексацияләү турында» 2008 елның 29 октябрендәге ПУ-544 номерлы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларны акчалата бүләкләүне индексацияләү турында» 2013 елның 26 сентябрендәге ПУ-940 номерлы указлары нигезендә арттырылган (индексацияләнгән) акчалата бүләкләүне 2017 елның 1 октябреннән 1,049 тапкыр арттырырга (индексацияләргә).

2. Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның айлык акчалата бүләкләүләрен күтәргәндә (индексацияләгәндә), аларның

күләме, шулай ук айлык акчалата бүләкләр күләме арттыру ягына бөтен бер сумга кадәр түгәрәкләнергә тиеш, дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына әлеге Указны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны Татарстан Республикасы бюджетында тиешле финанс елына каралган бюджет ассигнованияләре күләмендә финанслауны тормышка ашырырга.

4. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ГОМУМИ БҮЛЕК ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2017 ел, 11 август
№ ПУ-667